## Июль аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2.45 | 4.15 | 13.05 | 18.24 | 21.13 | 22.43 |
| 2 | 2.46 | 4.16 | 13.05 | 18.24 | 21.13 | 22.43 |
| 3 | 2.47 | 4.17 | 13.05 | 18.24 | 21.12 | 22.42 |
| 4 | 2.48 | 4.18 | 13.05 | 18.23 | 21.12 | 22.42 |
| 5 | 2.49 | 4.19 | 13.05 | 18.23 | 21.11 | 22.41 |
| 6 | 2.50 | 4.20 | 13.05 | 18.23 | 21.11 | 22.41 |
| 7 | 2.50 | 4.20 | 13.05 | 18.23 | 21.10 | 22.40 |
| 8 | 2.51 | 4.21 | 13.05 | 18.22 | 21.09 | 22.39 |
| 9 | 2.52 | 4.22 | 13.05 | 18.22 | 21.09 | 22.39 |
| 10 | 2.54 | 4.24 | 13.05 | 18.22 | 21.08 | 22.38 |
| 11 | 2.55 | 4.25 | 13.05 | 18.21 | 21.07 | 22.37 |
| 12 | 2.56 | 4.26 | 13.05 | 18.21 | 21.06 | 22.36 |
| 13 | 2.57 | 4.27 | 13.05 | 18.20 | 21.05 | 22.35 |
| 14 | 2.58 | 4.28 | 13.05 | 18.20 | 21.04 | 22.34 |
| 15 | 2.59 | 4.29 | 13.05 | 18.19 | 21.03 | 22.33 |
| 16 | 3.01 | 4.31 | 13.05 | 18.19 | 21.02 | 22.32 |
| 17 | 3.02 | 4.32 | 13.05 | 18.18 | 21.01 | 22.31 |
| 18 | 3.03 | 4.33 | 13.05 | 18.18 | 21.00 | 22.30 |
| 19 | 3.05 | 4.35 | 13.05 | 18.17 | 20.58 | 22.28 |
| 20 | 3.06 | 4.36 | 13.05 | 18.16 | 20.57 | 22.27 |
| 21 | 3.08 | 4.38 | 13.05 | 18.16 | 20.56 | 22.26 |
| 22 | 3.09 | 4.39 | 13.05 | 18.15 | 20.54 | 22.24 |
| 23 | 3.10 | 4.40 | 13.05 | 18.14 | 20.53 | 22.23 |
| 24 | 3.12 | 4.42 | 13.05 | 18.13 | 20.51 | 22.21 |
| 25 | 3.13 | 4.43 | 13.05 | 18.12 | 20.50 | 22.20 |
| 26 | 3.15 | 4.45 | 13.05 | 18.12 | 20.48 | 22.18 |
| 27 | 3.17 | 4.47 | 13.05 | 18.11 | 20.47 | 22.17 |
| 28 | 3.18 | 4.48 | 13.05 | 18.10 | 20.45 | 22.15 |
| 29 | 3.20 | 4.50 | 13.05 | 18.09 | 20.44 | 22.14 |
| 30 | 3.21 | 4.51 | 13.05 | 18.08 | 20.42 | 22.12 |
| 31 | 3.23 | 4.53 | 13.05 | 18.07 | 20.40 | 22.10 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре өзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*

**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

# КЫЙБЛА

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 6
2012 ел
июнь

№ 26 (1153), 23 июнь 2012 ел

ВӘГАЗЬ

## Гаилә серләре

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Кешелек дөньясының иң беренче нигезе булып гаилә тора. Хакыйкый яшәешнең төзелеше өчен терәүләр буларак Аллаһы Тәгалә ир белән хатынны яралткан.

Ислам дине ирләрдән хатын-кызларга карата һәрвакыт күркәм мөгамәләдә булуны таләп итә. Шул ук вакытта хатын-кызларга да шәригать кысаларында үз ирләренә буйсынырга боера.

Ир белән хатын арасындагы мөгамәлә үзара сөешү һәм мәрхәмәтлелеккә корылырга тиеш. Чөнки тормыштагы бөтен уңыш бер-береңне аңлау, сөю, гафу итә белү һәм үзара мәрхәмәтле булудан килә.

Әгәр ир белән хатын бер-берсен сөеп, бер-берсеннән разый булып һәм бер-берсенең тиешле хакларын үтәп гомер итсәләр, шәригать юлыннан аерылмыйча һәрвакыт бер-берсенә тугры, ышанычлы иптәш булсалар, дөньяда бәхетле рәхәт гомер итүләре өстенә кыяметтә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләренә ирешәчәкләр.

Исламда никах бәйләнеше, хисләрнең бер мизгелгә кабынуыннан һәм хайвани теләкләрнең тәэсиреннән югарырак урында тора. Әгәр хакыйкый мөселманга үзенең хатыны белән булган мөнәсәбәтләрендә нәрсәдер ошамаган икән, ул ачуга бирелүдән һәм буш кешегә генә хас вакчыллыклардан ерак тора, намус, түземлелек, күңел киңлеге һәм күркәм әхлак сыйфатларына ия була.

Динебездә хатын алу һәм аеру дөрес булса да, һичбер сәбәпсез хатын аеруны Аллаһы Тәгалә сөйми. Кайбер кардәшләребез: «Никах та дөрес, талак да дөрес», - диләр. Әйе, өйләнү дә, аеру да дөрес, әмма бердән артык хатын алуның, алганын аеруның дөрес булуы ни дигән сүз соң? Бу нәрсәләр ни өчен рөхсәт ителгән, хикмәте нәрсәдә, шуны аңлыйбызмы икән?

Талак нәфескә генә ияреп хәл кылына торган нәрсә түгел, бәлки, ул вәзгыятьне төзәтү, әдәп-инсафны алга җибәрү өчен бирелгән бер коралдыр. «Иң соңгы дару - тимер кыздырып басу», дигән әйтемдәге кебек, талак та иң актык чиктә генә кулланыла торган бер юл. Әгәр талак мәсьәләсендә бары тик үз кәефебезне генә саклап эш кылсак, Аллаһы Тәгалә каршында иң ачулы булган хәләлне сайлаган булырбыз.

Өйләнешкән вакытта һәрбер ир, яхшы һәм итагатьле, үзенә ошый торган бер хатын алуны, шулай ук һәрбер хатын-кыз үзе барачак ир-егетнең мәрхәмәтле, мөлаем, үзләрен яхшы тәрбия кылырлык, җил-яңгыр тидермәслек булуын телиләр. Бу хакта бөтен көчләре белән тырышалар һәм һәртөрле чаралар күрәләр. Әмма шулкадәр тырышулар белән дә кайвакыт эшләр теләгән рәвештә булмаска мөмкин. Башларына шундый бәла килгән ир белән хатын ни эшләсеннәр? Бу авыр вәзгыятьтән чыгу юлы бармы? Әгәр булса, ничек итеп?

Бу мәсьәләдә шәригатебездә түбәндәге биш юл билгеләнгән:

Беренче юл - ир белән хатынның сабыр кылулары. Аралары никадәр нык бозылса да, ир белән хатын чын күңелләре белән сабыр итәргә, аерылуда булган зарар һәм файдаларны яхшылап үлчәргә тиешләр. Бәлки, шушы сабыр итү һәм үлчәү сәбәбеннән ир белән хатын үзләренең ялгыш юлга кергәнлекләрен аңлап, үз фикерләреннән кайтырлар һәм мәслихәт юлын тотарлар.

Табигатьләре бер-берсенә мәгълүм булмаган кешеләр күп вакытта беренче аралашуларында үзара килешә алмасалар да, әмма соңыннан араларында өлфәт һәм дуслык хасил була. Иң әүвәлге суыклык һәм илтифатсызлык сәбәпле ир белән хатынның аерылышуы дөрес эш түгел. Чөнки моннан соң алачак хатын, яки торачак ир белән дә шундый ук хәл булырга мөмкин. Әгәр шул әүвәлге вакыйгада бераз сабыр итү сәбәпле эш төзәлеп китсә, икенче мәртәбә мәшәкатькә очраудан иминлек булыр. Әүвәлге елларында бик начар торып та, соңыннан аралары төзәлеп киткән ир белән хатын дөньяда аз түгел. Шуның өчен әүвәлге бизешү белән аерылышырга тырышмаска, бәлки, берникадәр вакыт сабыр итәргә кирәк.

Икенче юл - әгәр ир белән хатын сабыр итә алмасалар, яки сабыр итүдән файда күрелмәсә, ул вакытта эшне казый хөкеменә тапшырырга кирәк. Казый ир белән хатын арасындагы мәхәббәтсезлекнең сәбәпләрен нечкәләп тикшерер һәм сәбәпләрен тапканнан соң, кулыннан килгән кадәр чаралар белән араларын төзәтергә тырышыр. Ихтимал ки, гаепле тараф бу вакытта үзенең